Раслыйм:
Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
“Почкучук урта мәктәбе” муниципаль
бюджет гомуми белем учреждениесе
директоры_____________А.В.Файзрахманов

Педагоглар киңәшмәсе №1
Беркетмәсе №1 26 август 2020ел
Боерык № 42

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе «Почкучук урта гомуми белем бирү мәктәбе» Кнә-Баш авылы мәктәпкәчә әзерлек төркеменең
(мәктәпкәчә белем бирү программасы буенча)

# 2020-2021 нче уку елына укыту-тәрбия планы

**Еллык планның эчтәлеге**

| **Эш төре** |
|---|
| **I.** 2019-2020 нче уку елына анализ |
| **II.** 2020-2021 нче уку елына бурычлар |
| **III.** Социаль активлыкны эш квалификациясен күтәрү |
| **IV.** Методик эш **1.**Методик киңәшмәләр |
| **2.** Укыту- тәрбия процессында педагогик контроль |
| **3.**Киңәшләр |
| **4.** Ачык чаралар |
| **5.**Күргәзмәләр |
| **6.** Конкурслар |
| Алдынгы педагогик тәҗрибәне өйрәнү, тарату. |
| **V.** Ата-аналар белән эш **1.**Гомуми ата-аналар җыелышы,төркемнәрдә җыелышлар |
| **2.**Киңәшләр, Күргәзмәләр |
| Семинар-практикум |
| **VI.** Бала хокукын саклау, яклау эшен тормынка ашыру планы |
| **VII.** Административ хуҗалык эшләре планы |
| **VIII.** Хезмәт күрсәтү персоналы белән эш |
| Еллык планга кушымталар: |
| **1.**Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында Татарстан Республикасы законын тормышка ашыру буенча эш планы |
| **2.** Балалар бакчасында хезмәтне саклау һәм техник куркынычсызлык буенча эш планы |
| **3.**Балаларның сәламәтлеген саклау буенча эш планы |
| **4.** Сәләтле балалар белән эш планы |
| **5.** Балаларга патриотик тәрбия бирү буенча эш планы |
| **6.** ГО, гадәттәнтыш хәлләр һәм терроргa каршы эш планы |
| **7.** Җәйге чорга сәламәтләндерү планы |
| **8.** Коррупциягә каршы көрәш буенча алып барылучы эш |
| **9.** Җәйге сәламәтләндерү чорына эш планы |

# I . 2019 – 2020 уку елына анализ.

**Кнә-Баш** авылы мәктәпкәчә тәрбия учреждениясе 1989 елдан эшли башлый.

Бер катлы типлаштырган агач бина башлангыч мәктәп белән бер түбә астында урнашкан.

Группа бүлмәләре иркен, якты, эстетик зәвык белән җиһазландырылган. Төрле уен почмаклары бар. Дидактик уеннар өчен бай материал тупланган. Юл хәрәкәте кагыйдәләре почмагы, табигать почмагы, керәшен почмагы балаларның культурасын формалаштырырга булыша.

15 балага исәпләгән балалар бакчасында бер катнаш группа, барлыгы 8 бала тәрбияләнде.

Балалар бакчасында т**әрбияче Фатыхова Гөлгенә Ваккас кызы – 12 ел педагогик стажлы, югары белемле.**

**Балалар бакчасында түбәндәге программалар нигезендә эш алып барылды:**

Балалар бакчасының **төп программалары**:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе «Почкучук урта гомуми белем бирү мәктәбе» Кнә-Баш авылы мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү учреждениесенең белем бирү программасы.
2. “От рождения до школы” (под ред. Н.Е.Вераксы, М.А.Васильевой, Т.С.Комаровой , Москва, 2014 год).

**Өстәмә программалар**:

1. Р.Ф. Хәзрәтова, З.Г. Шәрәфетдинова, И.Җ. Хәбибуллина, “Туган телдә сөйләшәбез”, Казан, Тат. Китап нәшер., 2013 ел.

Зарипова З.М. “Туган телдә сөйләшәбез”, Казан, Тат. Китап нәшер., 2013 ел.

2. С.М. Гаффарова, Г.З.Гарафиева, Д.С. Гарипова, Г.М.Билалова, Р.Ф.Нигматуллина, З.Ф.Бадуртдинова “Изучаем русский язык”, Казан , 2011г.
3. Р.К.Шаеххованың “Авазларны уйнатып”, Казан 2011 ел
4. О.А. Соломенникова “Ознакомление с природой в детском саду” 2015 г.
5. “Основы безопасности детей дошкольного возраста” (Н.Авдеева, О.Князева, Р.Стеркина, 1995 г).
6. “Программа воспитания и обучения в детском саду” (под ред.М.А.Васильевой, В.В.Гербовой, Т.С.Комаровой – 3е изд., испр.и доп. – М.Мозаика – Синтез, 2005 год)
7. Дыбина О.В. “Ознакомление с предметным и социальным окружением”
8. “Математические ступеньки” Колесникова Е.В. Москва, 2008 г.

**Узган уку елында балалар бакчасы түбәндәге методик бурычларны үтәүне үз өстенә алды:**

1. Балаларның яшь һәм үсеш дәрәҗәсен исәпкә алып, сәламәт яшәү күнекмәләрен формалаштыруга юнәлдерелгән белем бирү эшчәнлеген киңәйтү һәм камилләштерү.

2. Мәктәпкәчә белем бирүдә федераль дәүләт белем бирү стадартларын куллану.

3. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә балаларны ике дәүләт теленә дә камил өйрәтү өчен яңа укыту- методик комплектларны куллану.

Оста һәм тәмле ризык пешерүче, пешекче – Шарафеева Ләйлә Рәҗәп кызы, һәм һәрвакыт чисталык, тәртиплелек урнаштыручы кече тәрбиячесе Фатхуллина Гузәл Садыйк кызы эшләде.

Квартал саен укыту-тәрбия эшендә куелган бурычлар каралды, түбәндәге темаларга ***педагогик киңәшмәләр*** уздырылды:

1. Балалар бакчасының яңа уку елына әзерлеге.
2. Балаларның тормышларын, сәламәтлекләрен саклауга игътибарны көчәйтү.
3. Уку елына йомгак ясау.

Тәрбия эше нәтиҗәсе булсын өчен балалар бакчасы һәм гаилә бербөтен булып эш итәргә тиеш. Коллективта эти-әниләр белән эшләүгә зур игътибар бирелде. Әтиләр ремонт вакытында зур ярдәм күрсәттеләр. Бәйрәмнәрдә эти-әниләр төп кунакларыбыз булалар.

Әти-әниләр белән түбәндәге план буенча җыелышлар уздырылды:
1. Яңа уку елы адында торган бурычлар.
2. Федераль дәүләт белем бирү стандартлары турында мәгълумат бирү.
3. 2019 – 2020 нче уку елына йомгак ясау.

Ата-аналар өчен киңәшләр уздырылды: балаларның режимы, киеме; уеннар роле; сәламәтләндерү күнегүләре турында сөйләшенде. Яшелчәләрдән, “Алтын куллар” күргәзмәсе , “Мы за мир на дорогах” рәсем күргәзмәсе , “Гаилә бәйрәме” уңаеннан рәсем күргәзмәсе оештырылды.

Ел дәвамында узучы бәйрәмнәр, ачык чаралар яки ачык дәрес итеп уздырылды: «Көз бәйрәме», «Яңа ел» бәйрәме, «Юлда сак бул» ачык дәрес, «Ватанны саклаучылар көне» бәйрәме, «Әниләр бәйрәме», «Һәр вакыт булсын кояш» дәресе үткәрелде.

Балалар күргәзмә һәм конкурсларда актив катнашты: Район күләмендә 1нче һәм 2нче урыннарны яуладылар.

Балалар бакчасыннан мәктәпкә кергән балаларның уку нәтиҗәләре:

| Еллар | 2017 – 2018 | 2018 – 2019 | 2019 – 2020 |
|---|---|---|---|
| Балалар бакчасыннан киткән укучыларнын өлгереше | 90% | 95% | - |

Мәктәпкә 2019 нче уку елында балалар бакчасыннан мәктәпкә 2 бала керде.

Уку елы барышында балалар бакчасы балаларның тормышын саклау һәм сәламәтлекләрен ныгыту, организмнарын чыныктыру, балаларны дөрес итеп сыйфатлы тукландыру, культура – гигиена күнекмәләрен тәрбияләүне камилләштерү өстендә эшләде. Һәр аш алдыннан җиң сызганып кулны сабынлап юу, авыз чайкау, йокы алдыннан аякларны юу, һәр көн саф һавада булу гадәткә кертелде.

Физик тәрбия бирү дәресләре иртәнге гимнастика, спорт уеннары стандарт булмаган алымнар ярдәмендә күңелле һәм файдалы итеп оештырылды. 5-7 яшьлекләр белән физкультура дәресләре, спорт чаралары ел буена саф һавада үтте. Төп максатыбыз – балаларның күнегүләрне яратып эшләвенә, шатланып, күтәренке күңел белән башка режим моментларында да теләп катнашуына, һәр сабыйга “хәрәкәт шатлыгы” бирүгә ирешү. Балалар бакчасы үзенең ирешелгән уңышлары белән горурлана. Балаларның авырып бакчага килмәгән көннәре түбәндәгечә:

| Уку елы | Район күрсәткече | Балалар бакчасы буенча |
|---|---|---|
| 2017 | 3 | 2,6 |
| 2018 | 3 | 2,8 |
| 2019 | 3 | 2,2 |

Учреждениенең яшелчә бакчасы бар, анда җәйге чорда яшелчәләр үстерелде.

Территория иркен. Тимер челтәр койма белән әйләндереп алынган. Уен мәйданчылыгында җиһазлар булдырылган, спорт мәйданчыгы бар.

Административ-хуҗалык эшләре ел дәвамында алып барылды: территория һәрвакыт чистартылды, инвентарьләрнең төзеклеге тәимин ителде, бакча эшләре эшләнде.

Ел әйләнәсендә бүлмәләрдә яктылык җылылык, һава режимы саклана. Балалар бакчасы электр белән җылытыла.

Балалар белән ***"Т.Р. телләр турында законын"*** тормышка ашыру буенча ике юнәлештә эш алып барыла:

I.Татар һәм рус теленә өйрәтү.

II.Ике телдә дә тиеш дәрәҗәдә тәрбия процессын оештыру.

***Татар һәм урыс теленә өйрәтү өч юнәлештә алып барыла.***

1. Телне өйрәнү.УМК куллану
2. Туган як һәм аның табигате белән таныштыру.
3. Татар һәм урыс халкының мәдәнияте белән таныштыруны дәвам итү.

Шул ук вакытта, төрле дидактик һәм бармак уеннары кулланылды.Халык авыз иҗатын өйрәнү киң кулланылды.

Баланы дөрес сөйләргә өйрәтү, аның сүз байлыгын арттыру, үз фикерен башкаларга ачык , аңлаешлы итеп сөйләргә өйрәтү балалар бакчасының төп бурычы булып тора. Без даими рәвештә шул юнәлештә эш алып барабыз. Моның өчен УМК киң кулланыла, ягъни, без ана телендә мультфильмнар карыйбыз, хикәяләр, әкиятләр укыйбыз һәм балалар белән бергә эчтәлеген сөйләп карыйбыз,сюжетлы-рольле, хәрәкәтле һәм түгәрәк уеннар уйныйбыз. Җырлар өйрәнәбез , шигырьләр ятлыйбыз. Картиналар буенча хикәяләр төзергә өйрәнәбез. Сәнгатьле сөйләм, кычкырып уку, хикәя төзеп сөйләү кебек эшләрне башкарганда авазларны дөрес әйтү беренче урынга куела.

Белгәнебезчә, бала ана телендә камил сөйләшергә өйрәнсен өчен гаиләдә дә эшне дәвам итәргә кирәк. Шуңа күрә без әти-әниләр белән бергәләп эш алып барырга омтылабыз. УМК составына кергән мультфильмнарны өйдә карарга биреп җибәрәбез. Балалар бакчасында өйрәнгән шигырьләрне ныгыту өчен өйгә алырга тәкъдим итәбез.

Йомгаклап шуны әйтәсем килә, балалар бакчасында тәрбия-өйрәтү эше җитәрлек дәрәҗәдә куелган, балаларны өйрәтү, төрле яклап үстерү һәм тәрбияләү эшенә зур игътибар бирелә, уңай шартлар тудырылган. Ел дәвамында балалар бакчасының матди - техник хәле тагын да яхшырды. Гомумән алганда балалар бакчасының еллык эше тиешле югарылыкта дип нәтиҗә ясалды. Уңай эшләребез белән бергә, әле чишелешен табасы, проблемаларыбыз да шактый. Бакчабызда ремонт эшләре алып барырга кирәк. Тәрбияченең дә үз өстендә эшләүләрен яхшырту, һөнәри осталыкларын тагын да камилләштерү таләп ителә.

**МЕТОДИК ТЕМА:**

***“Мәктәпкәчә белем бирүнең яңа стандартлары нигезендә, мәктәпкәчә яшьтәге балаларга тәрбия һәм белем бирү эшчәнлегенең эффектлыгын тәэмин итү өчен педагогларның һөнәри осталыкларын камилләштерү".***

## II. 2020 – 2021 нче уку елына бурычлар:

1. Балаларны ике дәүләт теленә өйрәтү буенча эшчәнлекне ФДББС таләпләренә туры китереп оештыру. УМК ны нәтиҗәле файдалану аша кызыксыну тәрбияләү.

2. Балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, аларның физик һәм психик үсешен тәэмин итү, сәламәт яшәү рәвеше һәм иминлек нигезләренә төшендерү.

3. Үстерешле тирәлек булдырып, балаларга хезмәт тәрбиясе бирү аша, беренчел һөнәр үзләштерүдә үзбилгеләнүләренә этәргеч ясау.

## ЭШНЕҢ ЮНӘЛЕШЛӘРЕ

- Балаларның физик һәм психик сәламәтлеген ныгыту һәм саклау, организмның адаптцион мөмкинлекләрен үстерү, шәхеснең физик культура нигезләрен, сәламәт яшәү рәвешенең кыйммәтләрен формалаштыру.
- Белем бирү эшчәнлегенен рациональләштерү процессында педагогларның профессиональ компетенциясен күтәрү.
- Бүгенге җәмгыятьтә шәхес буларак формалашу процессында балаларның һөнәри үзбилгеләнүләрен тәэмин итү, социаль мөнәсәбәтләр системасына кертү өчен алшартлар тудыру, эзләнүчән, иҗади фикер йөртә белүче, ватанпарвәр балалар тәрбияләү, аларга хезмәт тәрбиясе бирү.

## III. Социаль активлыкны эш квалификациясен күтәрү

| № | Эш төре | Вакыты | Җаваплы | Үтәлеше |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Район методик берләшмәләрендә катнашу | Мәгариф идәрәсе графигы буенча | Гараева Г.А.(Директор урынбасары) | |
| 2. | Методик әдәбиятны өйрәнү | Ел дәвамында | Тәрбияче Фатыхова Г.В. | |
| 3 | Инновацион эшчәнлек. Яңа авторлык программаларын куллану буенча район һәм республика буенча үткәрелә торган консультация, семинар, конференцияләрдә катнашу | Ел дәвамында | Директор урынбасары Тәрбияче | |
| 4 | Мәгәриф эшчәннәренең август киңәшмәсендә катнашу | Август | Директор урынбасары, Тәрбияче | |
| 5 | Район методик берләшмә семинарларында катнашу | Мәгариф бүлеге планы буенча | Директор урынбасары, Тәрбияче | |
| 6 | Квалификацияне күтәрү курсларына тәрбиячеләрне җибәрү | График буенча | Директор урынбасары | |

## IV Методик эш
### мәктәпкәчә белем бирү буенча директор урынбасары каршында методик киңәшмә

| № | Эш төре | Җаваплы кеше | Вакыты | Үтәлеше |
|---|---|---|---|---|
| **I** | **Мәктәпкәчә белем бирү эшен оештыру.** | Гараева Г.А. | Август | |
| | 1. Еллык эш план белән таныштыру. | | | |
| | 2. Мәктәпкәчә белем бирүдә укыту – тәрбия программаларын тәгаенләү. | | | |
| | 3. Тәрбия белем бирү процессының эчтәлеген ФДББС таләпләренә туры китереп, УМК ын нәтиҗәле куллану. | | | |
| | 4. Шөгыль бүленешләрен, укыту планын, эш графигын тикшерү, тәрбиячеләрнең эш программаларын карау. Группаларны тәгаенләү. | | | |
| | 5. 2020-2021 нче уку елында Коррупциягә каршы, терроризмнан саклану буенча еллык эш планары белән танышу. | | | |
| **II** | **Балаларда ана телендә һәм икенче дәүләт теле буларак рус телендә аралашуга үстерелешле телләр тирәлеге тудыру.** | Гараева Г.А.. | Декабрь | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 1. Балаларны ике дәүләт теленә өйрәтү буенча эшчәнлекне ФГОС таләпләренә туры китереп оештыру.<br>2. УМК мөмкинлекләреннән файдаланып балаларның сөйләм культурасын үстерү.<br>3. Тематик контроль нәтиҗәләре. | | | |
| III | **Еллык эшнең нәтиҗәләре.** | Гараева Г.А. | Май | |
| | 1. Уку елының бурычлары үтәлеше. | | | |
| | 2. Төркем тәрбиячеләренең еллык эшенә отчетлары (диагностика нәтиҗәләре). | | | |
| | 3. 2020-2021 нчы уку елында балаларның бакчага йөрешенә анализ. | | | |
| | 4. Җәйге чорга сәламәтләндерү планын, эш графигын төзү. | | | |

## 2. Тәрбиячеләрнең балалар белән эшләвен өйрәнү

### Тематик тикшерүләр

| № | Эш төре | Җаваплы кеше | Вакыты | Үтәлеше |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм үстерү юнәлешен тормышка ашыруда УМК куллану. | Гараева Г.А. тәрбияче | Декабрь | |
| 2 | Хезмәт тәрбиясендә проект эшчәнлеге (мәктәпкә әзерлек төркеме) | Гараева Г.А. тәрбияче | Март | |

| № | Эш төре | Вакыты | Җаваплы | Үтәлеше |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Барлык төркемнәрнең яңа уку елына әзерлекләрен, тәрбиячеләрнең дәрескә әзерлеген тикшерү. | Уку елы башында | Гараева Г.А. | |
| 2. | Режим моментларын карау һәм анализлау. | Сентябрь, | Гараева Г.А. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Октябрь | | |
| 3. | Физик үсеш эшчәнлегенә оператив контроль | Сентябрь | Гараева Г.А. | |
| 4. | “Сөмбелә” бәйрәме иртәсенә анализ | Октябрь | Гараева Г.А. | |
| 5. | УМК кулланып сөйләм телен үстерү юнәлешендә балаларның шигырь өйрәнүләренә анализ. | Ноябрь | Гараева Г.А. | |
| 6. | Саф һавада йөрүне оештыру һәм башкаруга анализ. | декабрь | Гараева Г.А. | |
| 7. | Балалар бакчасындагы балаларның туклапу процессына анализ. | Январь | Гараева Г.А. | |
| 8. | Эстететик – сәнгати үсеш (җыр) шөгеленә анализ ясау. | Февраль | Гараева Г.А. | |
| 9. | Культура-гигиена таләпләрен үтәүгә анализ | Март | Гараева Г.А. | |
| 10. | Хезмәт эшчәнлеген күзәтүгә анализ | Апрель | Гараева Г.А. | |
| 11. | Яңа уку елына әзерлеккә анализ | май | Гараева Г.А. | |

**Киңәшләр**

| № | Эш төре | Җаваплы кеше | Вакыты | Үтәлеше |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Тәрбия һәм белем бирүдә Федераль дәүләт белем бирү стандартларын нәтиҗәле куллану. | Гараева Г.А. | Сентябрь | |
| 2 | Көнкүрештә, социумда, табигатьтә үз-үзеңне имин тоту нигезләре. | Фатыхова Г.В. | Октябрь | |
| 3 | Үсешкә булышлык итүче сөйләм мохите булдыру. | Гараева Г.А. | Октябрь | |
| 4 | Хезмәтнең төрле төрләрен башкарганда иҗадилык һәм инициативалылыкны үстерү. | Фатыхова Г.В. | Декабрь | |
| 5 | Проектлау эшчәнлеген үстерү өчен предмет-тирәлек мохите оештыру үзенчәлекләре. | Фатыхова Г.В. | Февраль | |

**Ачык чаралар.**

| № | Эш төре | Җаваплы кеше | Вакыты | Үтәлеше |
|---|---|---|---|---|
| 1 | “Белем бәйрәме” | Тәрбияче | Сентябрь | |
| 2. | Алтын көз “ Сөмбелә” | Тәрбияче | Октябрь | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3. | “Әнием - газизем”әниләр көне уңаеннан уздырылган кичә | Тәрбияче | Ноябрь | |
| 4. | “Кыш бабай бездә кунакта” (Яңа ел кичәсе) | Фатыхова Г.В. Гараева Г.А. | Декабрь | |
| 5. | “Әтиләр бәйрәме” (Ватанны саклаучылар көненә багышлана) | Гараева Г.А. Фатыхова Г.В. | Февраль | |
| 6. | Әбиләр һәм әниләр (8 март уңаеннан) | Гараева Г.А. Фатыхова Г.В. | Март | |
| 7. | “Туган телем – Тукай теле” (Тукай туган көнгә багышлана) . | Гараева Г.А. Фатыхова Г.В. | Апрель | |
| 8. | “Батырлык дәресе” (Җиңү көненә багышлап) | Гараева Г.А. Фатыхова Г.В. | Май | |
| 9. | “Без - яклауга мохтаҗ” (Балаларны яклау көненә багышлана) | Гараева Г.А. Фатыхова Г.В. | Июнь | |

**Күргәзмәләр**

| № | Эш төре | Җаваплы кеше | Вакыты | Үтәлеше |
|---|---|---|---|---|
| 1 | «Алтын көз» балаларның тематик рәсем күргәзмәсе | Тәрбияче | Октябрь | |
| 2 | Әниләр көненә багышланган «Минем яраткан әнием» дигән рәсем күргәзмәсе | Тәрбияче | Ноябрь | |
| 3 | “Кышкы матурлык” рәсем күргәзмәсе. | Тәрбияче | Декабрь | |
| 4 | Рус халык әкиятләре буенча ясалган рәсем һәм кул эшләре күргәзмәсе | Тәрбияче | Гыйнвар | |
| 5 | “Әти белән көчле мин” рәсем | Тәрбияче | Февраль | |
| 6 | Татар халык әкиятләре буенча ясалган рәсем һәм кул эшләре күргәзмәсе | Тәрбияче | Апрель | |
| 7 | « Матур Җәй, кил безгә!» - балалар рәсем күргәзмәсе | Тәрбияче | Март | |
| 8 | “Күңелле балачак” | Тәрбияче | Май- июнь | |

**Конкурслар**

| № | Эш төре | Җаваплы кеше | Вакыты | Үтәлеше |
|---|---|---|---|---|
| 1 | “Яшел территория” | Гараева Г.А. | Август | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2 | Пожарга каршы тематикага рәсем һәм аппликация конкурсы | Тәрбияче | Сентябрь | |
| 3 | Район күләмендә әниләр көненә багышлап уздырылган җыр һәм шигырь конкурсы | Гараева Г.А. Фатыхова Г.В. | Ноябрь | |
| 4 | Интеллектуальная спартакиада “Дошкольник” | Гараева Г.А. Фатыхова Г.В. | План буенча | |
| 5 | “Сәләтле бала” конкурсы | Гараева Г.А. Фатыхова Г.В. | План буенча | |
| 6 | Кышкы шәһәрчек (Кардан сыннар ясау) | Гараева Г.А. Фатыхова Г.В. | Декабрь | |
| 7 | Район күләмендә юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнү буенча уздырылган конкурс | Гараева Г.А. Фатыхова Г.В. | План буенча | |
| 8 | Караган мультфильмнардан рәсем конкурсы. | Фатыхова Г.В. | Декабрь | |
| 9 | Өйрәнелгән татар халык, рус халык әкиятләре буенча әти-әниләр белән берлектә рәсем конкурсы. | Фатыхова Г.В. | Январь | |
| 10 | Район күләмендә уздырылучы патриотик җыр һәм шигырь конкурсы. | Гараева Г.А. Фатыхова Г.В. | План буенча | |
| 11 | Г.Тукай туган көненә багышланган шигырь бәйгесе | Фатыхова Г.В. | Апрель | |
| 12 | “Ел тәрбиячесе” | Фатыхова Г.В. | План буенча | |

**Алдынгы педагогик тәҗрибәне өйрәнү, тарату**

| № | Эш төре | Җаваплы | Вакыты | Үтәлеше |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Яңа укыту- методик комплектларны кулланып тәрбия һәм белем бирү. | Тәрбияче | Ел дәвамында | |
| 2 | Федераль дәүләт белем бирү стандартларын куллану өчен шартлар булдыру. | Гараева Г.А. Фатыхова Г.В. | Ел дәвамында | |
| 3 | Район күләмендә үткәрелгән КМО һәм РМО утырышларында, семинарларда катнашу һәм тәҗрибә уртаклашу буенча чыгышлар ясау. | Гараева Г.А. | Ел дәвамында | |
| 4 | Алдынгы педагогик тәҗрибәне чагылдырган матбугат белән танышып бару, өйрәнү, куллану. | Гараева Г.А. Фатыхова Г.В. | Даими | |
| 5 | Тәрбияченең эш тәҗрибәсен өйрәнү, районга тарату чараларын күрү | Гараева Г.А. Фатыхова Г.В. | Даими | |
| 6 | Белем һәм тәрбия бирү өчен дидактик уеннар һәм методик кулланмалар белән тулыландыру. | Гараева Г.А. Фатыхова Г.В. | Ел дәвамында | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| 7 | Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү өчен материаллар туплау | Гараева Г.А. Фатыхова Г.В. | Ел дәвамында | |
| 8 | Оештырылган күргәзмә материаллардан папкалар һәм альбомнар туплау | Гараева Г.А. Фатыхова Г.В. | Ел дәвамында | |

## V.Ата – аналар белән эш
### 1. Гомуми ата – аналар җыелышлары

| № | Эш төре | Җаваплы кеше | Вакыты | Үтәлеше |
|---|---|---|---|---|
| I | **Оештыру эшләре** | Гараева Г.А. Фатыхова Г.В. | Август | |
| | 1. Балалар бакчасының эшен башлап җибәрү, бурычлар, төркемнәрдәге режим,ата-аналарны эчке тәртип кагыйдәләре белән таныштыру. | | | |
| | 2. Укыту- тәрбия эшендә яңа буын программалары,УМК, ФДББС белән таныштыру. Ике дәүләт телен өйрәтүгә заманча караш. | | | |
| | 3. Балаларның иминлеген саклау. Балаларга беренчел хезмәт тәрбиясе бирү. | | | |
| II | **Балаларның җәйге ялларын оештыру** | Гараева Г.А. Фатыхова Г.В. | Май | |
| | 1. Балалар бакчасының еллык эшенә отчеты | | | |
| | 2. Җәй көне балаларның тормышын һәм сәламәтлеген саклау. | | | |

### 2. Катнаш төркемдә җыелышлар

| № | Эш төре | Җаваплы кеше | Вакыты | Үтәлеше |
|---|---|---|---|---|
| I | **Балаларның физик сәламәтлеге.**<br>1. Балаларга уку елы дәвамында куелучы таләпләр.<br>2. Әти - әниләр арасында анкета уздыру.<br>3.Баларның һөнәр сайлауда беренчел үзбилгеләнүләре | Фатыхова Г.В. | Ноябрь | |
| II | **Балаларны ана телендә һәм рус теленә өйрәтүдә әти-әниләрнең һәм балалар бакчасының бердәм эше.**<br>1.Баланы рус телендә хаталарсыз сөйләшергә өйрәтүдә тел шомарткычларның роле.<br>2. Өйдә ике телдә сөйләшү баланың сөйләм теле | Фатыхова Г.В. | Декабрь | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | үсешендә чагылышы. | | | |
| III | **2020-2021 нчы уку елына йомгак.**<br>1. Бала мәктәпкә әзерме?<br>2. Җәйгә планнар.<br>3. Җәйге чорда балаларның иминлеген тәэмин итү. Куркынычсызлык кагыйдәләре | Фатыхова Г.В. | Май | |

### 3. Ата – аналар өчен консультацияләр, әңгәмәләр

| № | Эш төре | Җаваплы кеше | Вакыты | Үтәлеше |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Мәктәп һәм балалар бакчасы арасында дәвамчанлык | Тәрбияче | Даими | |
| 2 | Мәктәпкәчә әзерлек төркеменең программаларны үзләштерү дәрәҗәләре | Тәрбияче | Ел дәвамында | |
| 3 | Гаилә - тәрбиянең нигезе | Тәрбияче | Даими | |
| 4 | Балаларда шәфкатлелек тәрбияләү | Тәрбияче | Даими | |
| 5 | Авазлар өстендә ничек эшләргә | Тәрбияче | Даими | |
| 6 | Баланы мәктәпкә ничек әзерләргә. | Тәрбияче | Ел дәвамында | |
| 7 | Балаларга хезмәт тәрбиясе бирү | Тәрбияче | Даими | |
| 8 | Балаларга нинди китаплар укырга | Тәрбияче | Даими | |
| 9 | Әдәп төбе – матур гадәт | Тәрбияче | Ел дәвамында | |
| 10 | Баланың сәламәтлеген ничек ныгытырга. | Тәрбияче | Даими | |
| 11 | Көйсез бала белән нишләргә? | Тәрбияче | Даими | |

### 4.Үрнәк гаиләләр белән эш

| № | Эш төре | Җаваплы кеше | Вакыты | Үтәлеше |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ата – аналар җыелышларында тәҗрибә уртаклашулар оештыру. | Фатыхова Г.В. | График буенча | |
| 2 | “Гаилә кыйммәтләре” әңгәмә | Фатыхова Г.В. | Февраль | |
| 3 | “Олыласаң олыны, олыларлар үзеңне” дип исемләнгән кичә | Гараева Г.А. | Март | |

### 5. Күргәзмәләр

| № | Эш төре | Җаваплы кеше | Вакыты | Үтәлеше |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Әти - әниләр өчен тәрбия китапларыннан күргәзмә. | Гараева Г.А. | Даими | |
| 2 | “Көз бүләге” | Фатыхова Г.В. | Октябрь | |
| 3 | “Кышкы матурлык” | Гараева Г.А.<br>Фатыхова Г.В. | Декабрь | |
| 4 | “Әти булдыра, Әти барысында булдыра” | Гараева Г.А.<br>Фатыхова Г.В. | Февраль | |
| 5 | “Әниемнең кул эшләре” | Фатыхова Г.В. | Март | |
| 6 | “Мин бәхетле бала” | Фатыхова Г.В. | Май | |

### СЕМИНАР – ПРАКТИКУМ

**Тема:УМК кулланып, дәүләт телләренә өйрәтү эшен системалаштыру**

| № | Эш төре | Җаваплы | Вакыты | Үтәлеше |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны Татарстан Республикасы дәүләт телләренә өйрәтүдә укыту-методик комплектларның роле. | Гараева Г.А. Фатыхова Г.В. | Октябрь | |
| 2. | Укыту-методик комплектларны төркемнәрдә куллану. | Тәрбияче | Даими | |

## ТӘРБИЯЧЕЛӘР ӨЧЕН КОНСУЛЬТАЦИЯЛӘР ТЕМАТИКАСЫ

| **№** | Эш төре | Җаваплы | Вакыты | Үтәлеше |
|---|---|---|---|---|
| **1. Укыту процессын тулыландыру** | | | | |
| 1 | Белем – тәрбия бирү эшен федераль дәүләт белем бирү стандартларына туры китереп оештыру. Белем бирү эшен планлаштыруда яңалыклар белән таныштыру . | Гараева Г.А. | Ел дәвамында | |
| **2. СанПиН таләпләрен үтәү** | | | | |
| 1 | Ата-аналар белән берлектә балаларны сәламәтләндерү эшен оештыру. Яңа СанПиН таләпләре белән таныштыру. | Гараева Г.А. | Сентябрь | |
| 2 | Балаларны дөрес чыныктыру. | Тәрбияче | Октябрь | |
| 3 | Еш авыручы балаларны сәламәтләндерү. | Тәрбияче | Ноябрь | |
| **3. Сәламәтлек педагогикасы күзлегеннән чыгып, белем процессын тулыландыру** | | | | |
| 1 | Мәктәпкәчә яшьтәге бала организмын ныгытуда физкультура шөгыльләренең роле. | Гараева Г.А. | Ноябрь | |
| 2 | Хәрәкәт активлыгын үстерүче уеннар. | Тәрбияче | Декабрь | |
| **4. Балаларны ике дәүләт теленә өйрәтүне оештыру** | | | | |
| 1 | Сөйләм күнекмәләрен үстерүдә УМК куллану. | Тәрбиячеләр | Сентябрь | |
| 2 | Төркемнәрдә индивидуаль эш оештыру. | Тәрбиячеләр | Ноябрь | |
| 4 | “Уйный-уйный тел ачыла” – уеннар аша балаларның сөйләм телләрен үстерү. | Тәрбиячеләр | Декабрь | |
| 5 | Сәнгатьле уку. | Тәрбиячеләр | Апрель | |
| 6 | Сөйләм телен үстерүдә үстерелешле уеннарның роле. | Тәрбиячеләр | Апрель | |
| **5. Музыкаль – эстетик эшчәнлекне оештыру** | | | | |
| 1 | Музыка белем бирү эшчәнлегендә җырлау сәләтен үстерү. | Фатыхова Г.В. | Февраль | |
| **6. Социаль – эмоциональ үсеш проблемасы** | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Адаптация чорын җиңел үтү юллары. | Фатыхова Г.В. | Сентябрь | |
| 2 | Оялчан балага ярдәмгә. | Фатыхова Г.В. | Ноябрь | . |
| 3 | Гиперактив балалар белән эшләү. | Фатыхова Г.В. | Декабрь | |
| 4 | Әкрен балага ничек ярдәм итәргә? | Гараева Г.А. | Февраль | |

## VI. Бала хокукын саклау, яклау эшен тормышка ашыру планы

| № n/n | Эш төре | Җаваплы кеше | Вакыты | Үтәлеш |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Балаларны яшьләренә карап группаларга туплау | Гараева Г.А. | Август | |
| 2 | Методик пособиеләр, прог – раммалар, күрсәтмә әсбаплар белән тәэмин итү | Гараева Г.А. | Сентябрь | |
| 3 | Ягу системасын тикшереп тору | Гараева Г.А. | Ел буе | |
| 4 | Инвентарьларны барлау | Гараева Г.А. | Даими | |
| 5 | Туклануны камилләштерү | Тәрбиячеләр | Сентябрь | |
| 6 | Сәламәтлек группасын билгеләү | Тәрбиячеләр | Ел буе. | |
| 7 | Балалар бакчасына йөрмәүче балалар белән эшне оештыру | Гараева Г.А. | Квартал саен | |
| 8 | Группадагы җиһазларны, эш коралларын карап, тикшереп тору. | Гараева Г.А. | Даими | |
| 9. | Участокта булган корылмаларны төзәтеп, яңартып тору | Гараева Г.А. Фатыхова Г.В. | Сентябрь | |
| 10. | Җәйге чорга сәламәтләндерү планын төзү | Тәрбиячеләр | Май | |
| 11. | Группа эшен оештыру | Тәрбиячеләр | Август | |
| 12. | Диспансеризация уздыру | Гараева Г.А. | График буенча | |
| 13. | Участокның торышын тикшерү | Хезмәткәрләр | Май-Август | |

## VII. Административ – хуҗалык эшләре планы

| № | Эш төре | Җаваплы | Вакыты | Үтәлеше |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Балалар бакчасының эшчеләр җыелышы | Август | Хезмәткәрләр | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | уздыру. Яңа уку елына хәзерлек. | | | |
| 2 | Группалардагы, йокы бүлмәләрендәге мебельләрнең маркировкаларын яңарту . | Сентябрь | Тәрбиячеләр | |
| 3 | Төркемнәрдә санитария-гигиена таләпләренең үтәлеше | Сентябрь | Хезмәткәрләр Тәрбиячеләр | |
| 4 | Приказ тәртибендә пожар куркынычсызлыгына җаваплы кешеләрне билгеләү | Сентябрь | МББ ДУ Тәрбиячеләр | |
| 5 | Бакчада электр приборларының төзеклелегенә контроль, эшчеләр белән әңгәмә. | Октябрь | МББ ДУ | |
| 6 | Бакчаның кышка әзерлеге буенча эшне оештыру (чәчәк орлыклары җыйнау, түтәлләрне казу, участокны чистарту, тәрәзәләрне ябыштыру, җылыту | Октябрь | Тәрбиячеләр хезмәткәрләр | |
| 7 | Яңа ел бәйрәмнәре уздырганда пожар куркынычсызлыгына каршы приказ буенча җаваплы кешеләр, кизү тору графигы төзү. | Декабрь | МББ ДУ | |
| 8 | Стендларны яңартып, тулыландырып тору. | Даими | Тәрбиячеләр | |
| 9 | Участокны кардан чистарту. | Январь, Март | МББ ДУ Тәрбиячеләр | |
| 10 | Электр приборларының төзеклелегенә контроль. | Январь | МББ ДУ Тәрбиячеләр | |
| 12 | Группадагы мебельләрнең куркынычсызлыгын тикшерү, ныгыту. | Февраль | Тәрбиячеләр | |
| 13 | ФГОС- таләпләренә туры китереп кулланма материаллар туплау | Даими | Тәрбиячеләр | |

## VIII.Хезмәт күрсәтү персоналы белән эш планы

| № | Эш төре | Җаваплы | Вакыты | Үтәлеш |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Хезмәтне саклау , эш вазыйфаларын үтәү, пожар куркынычсызлыгы, эчке тәртип кагыйдәләрен үтәү буенча инструктаж | Гараева Г.А. | Квартал саен | |
| 2 | Медосмотрларны вакытында торуны тәэмин итү | Гараева Г.А. | Елга 1 | |
| 3 | Көндәлек режимны саклау | Тәрбиячеләр | Даими | |
| 4 | Һәр хезмәткәрнең үз эшен җиренә җиткереп башкаруы өчен аңа мөмкинлекләр тудыру | Гараева Г.А. | Даими | |
| 5 | Хезмәткәрләр һәм балалар белән пожар куркынычсызлыгы буенча эвакуация уздыру | Гараева Г.А. | Елга 2 тапкыр | |
| 6 | Электр куркынычсызлыгы буенча укулар | Гараева Г.А. | Ноябрь | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | оештыру | | | |
| 7 | Бакча территориясендә яшелләндерү эшләрен оештыру | Фатхуллина Г.С. | Җәй айлары | |
| 8 | Санитар – гигиена кагыйдәләрен ныгыту буенча укулар оештыру | Гараева Г.А. | Декабрь | |

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ТЕЛЛӘРЕҺӘМ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАШКА ТЕЛЛӘР ТУРЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫН ТОРМЫШКА АШЫРУ БУЕНЧА ЭШ ПЛАНЫ

**МАКСАТ:** халык педагогикасына нигезләнеп, традицияләләр һәм гореф-гадәтләр аша балаларда туган илгә, туган телгә хөрмәт хисләре,телгә аңлы рәвештә милли – мәдәни хәзинә итеп карауны тәрбияләү; тел традицияләренә сакчыл мөнәсәбәт булдыру.

| № | Эш төре | Вакыты | Җаваплы | Үтәлеше |
|---|---|---|---|---|
| **Оештыру эшләре** | | | | |
| 1 | Төркемнәрне укыту-методик комплектлар, Федераль дәүләт белем бирү стандартлары буенча кулланмалар, күрсәтмә әсбаплар белән тулыландыру. | Ел дәвамында | МББ ДУ Тәрбияче ләр | |
| 2 | Мәгариф бүлеге буенча үткәреләчәк бәйгеләрдә катнашу. | Ел дәвамында | МББ ДУ Тәрбияче ләр | |
| 3 | Балаларны рус телендә һәм туган телдә дөрес сөйләшергә өйрәтү, яңа әсбаплар туплау. | Ел дәвамында | МББ ДУ Тәрбиячеләр | |
| 4 | Федераль дәүләт белем бирү стандартларын исәпкә алып эш планы төзү һәм педагогларны аның эчтәлеге белән таныштыру. | Сентябрь | МББ ДУ Тәрбиячеләр | |
| 5 | УМК буенча эш дәфтәрләре булдыру | Сентябрь | Тәрбиячеләр | |
| 6 | Район куләмендә уздырылган семинар,киңәшмә, ачык чараларда катнашу. | Ел дәвамында | Тәрбиячеләр | |
| 7 | Төркемнәрдәге милли почмакларны таләпләр нигезендә тулыландыру. | Ел дәвамында | Тәрбиячеләр | |
| **Педагоглар белән эш** | | | | |
| 1 | Балаларны дәүләт телләренә өйрәтү буенча индивидуаль эшне оештыру. | Ел дәвамында | Тәрбиячләр | |
| 2 | Балалар белән УМК кулланып эшләүдә төрле эш формаларын куллану. | Октябрь-ноябрь | Тәрбиячеләр | |
| 3 | “Минем эшемдә – УМК” темасына түгәрәк | Май | Тәрбиячеләр | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | өстәл. | | | |
| **Балалар белән эш** | | | | |
| 1 | Милли бәйрәмнәр үткәрү (еллык план буенча). | Ел дәвамында | Тәрбиячеләр | |
| 2 | Балалар белән эшләүдә УМК материалларын һәм методларын куллану. | Ел дәвамында | Тәрбиячеләр | |
| 3 | Төбәгебездә яшәүче әдипләрнең иҗатлары белән танышу. | Ел дәвамында | Тәрбиячеләр | |
| 4 | А.Алиш,М.Җәлил иҗаты белән танышу | Ел дәвамында | Тәрбиячеләр | |
| 6 | Әңгәмәләр үткәрү:<br>- "Татарстан минем республикам"<br>- "Казан – башкалабыз"<br>- "Минем туган авылым- Янилем" | Ел дәвамында | Тәрбиячеләр | |
| 8 | Г.Тукайнын туган көненә багышланган кичә. | Апрель | Тәрбиячеләр | |
| 9 | Г.Тукай туган көнгә багышланган шигырь бәйгесе | Апрель | Тәрбиячеләр | |
| | | | | |
| **Ата-аналар белән эш** | | | | |
| 1 | Яшь үзенчәлекләреннән чыгып төркемнәргә программа материаллары белән папкалар әзерләү. | Сентябрь | Тәрбиячеләр | |
| 2 | Төркемнәрдә милли традицияләр, милли бәйрәмнәргә багышланган әңгәмәләр үткәрү:<br>- "Балага туган телгә мәхәббәт уятуда ата-ананың роле"<br>- "Йолалар һәм традицияләр". | Ел дәвамында | Тәрбиячеләр | |
| 3 | Ата-аналарны милли бәйрәмнәргә чакыру. | Ел дәвамында | Тәрбиячеләр | |
| 4 | Ачык шөгыльләр күрсәтү. | Май | Тәрбиячеләр | |
| 5 | УМК буенча эш дәфтәрен өйдә куллану буенча консультация. | Ел дәвамында | Тәрбиячеләр | |
| 6 | Төркемнәрдә ата-аналар җыелышларында катнашу. | Даими | Тәрбиячеләр | |
| 7 | "Туган тел көне" – ата-аналар почмагы өчен мәгълүматлар | Февраль | Тәрбиячеләр | |
| 8 | УМК буенча материаллар чыганагы турында мәгълүматлар | Ел дәвамында | Мөдир | |

**Мәктәпкәчә тәрбия бирү төркемендә хезмәтне саклау һәм техник куркынычсызлык буенча эш планы**

| № | Эш төре | Җаваплы | Вакыты | Үтәлеше |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2020-2021 елларга төзелгән “Пожар куркынычсызлыгы” максатчан программасының үтәлеше турында отчет | МББ ДУ | Ярты елга 1 тапкыр | |
| 2 | Балалар белән булган бәхетсезлек очраклары турында отчет | МББ ДУ | Ярты елга 1 тапкыр | |
| 3 | Хезмәт урынында травма алу очраклары турында отчет | МББ ДУ | Ярты елга 1 тапкыр | |
| 4 | Техник персоналны электр куркынычсызлыгы буенча 1-2 нче квалификацион категориягә укыту. | МББ ДУ | Ноябрь | |
| 5 | Куркынычсызлык көне | Тәрбиячеләр | 01.09.20-04.09.20 | |
| 6 | “Игътибар – балалар” Бөтенроссия операциясе | Тәрбиячеләр | 24.08.20-28.09.20 | |
| 7 | Куркынычсызлык айлыгы | Тәрбиячеләр, МББ ДУ | 05.10.20-09.10.20 | |
| 8 | “Пожарга каршы” темага иң яхшы балалар рәсеме яисә аппликациягә республика конкурсының район этабы | Тәрбиячеләр | 01.10.20-01.11.20 | |
| 9 | Гражданлык хокукларын яклау айлыгы | Тәрбиячеләр, МББ ДУ | 04.09.20-04.10.20 | |
| 10 | Бөтендөнья юл хәрәкәтендә һәлак булучыларны искә алу көне | МББ ДУ | Ноябрь аеның соңгы якшәмбесе | |
| 11 | Балалар бакчалары мөдирләре өчен пожар куркынычсызлыгы буенча семинарда катнашу | Мөдир | Декабрь | |
| 12 | Хезмәтне саклау буенча чараларга тотылган чыгымнар турында отчет | МББ ДУ | 25.12.20 Кадәр | |
| 13 | Бөтендөнья хезмәтне саклау көне | Тәрбиячеләр | 28.04.21 | |
| 14 | Җитәкчеләр һәм хезмәткәрләрнең пожар-техник минимум буенча укулары | МББ ДУ | Май | |
| 15 | “Имин җәй” операциясе | Тәрбиячеләр | 01.06.21-31.08.21 | |
| 16 | Пожар чыккан очракта хезмәткәрләрне һәм балаларны эвакуацияләү планы буенча практик шөгыльләр | Тәрбиячеләр, МББ ДУ | Кварталга 1 тапкыр | |
| 17 | “Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы” темасына балалар рәсеме күргәзмәсе | Тәрбиячеләр | График буенча | |
| 18 | “Пожар куркынычсызлыгы”, “Хезмәтне саклау”, “Юл хәрәкәте иминлеге” стендларын яңарту. | Тәрбиячеләр, МББ ДУ | Октябрь | |

**Сәламәтләндерү һәм авыруларны кисәтү буенча еллык эш планы**

| № | Эш төре | Җаваплы | Вакыты | Үтәлеше |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Балаларның физик үсешен тикшерү | елга 2-4 тапкыр | Тәрбиячеләр | |
| 2. | Балаларның сәламәтлек торышын күзәтү: | даими | Тәрбиячеләр | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 1) Балаларны кабул итү вакытында;<br>2) яңа килгән балаларны кабул иткәндә; | | | |
| 3. | Физик тәрбиянең эффектлылыгын анализлау | елга бер тапкыр | Тәрбиячеләр | |
| 4. | Сәламәтләндерү чаралары:<br>1. Витаминотерапия.<br>3. Температура үзгәрүенә карап балаларны саф һавада кабул итү<br>4. Саф һавада гимнастика үткәрү<br>5. Гриппка каршы прививка ясау | <br>План буенча<br>Инфекция чорында<br>Даими | Тәрбиячеләр | |
| 5. | Физик тәрбия һәм чыныктыру чаралары:<br>1. Һава, кояш ванналары<br>2. Сәламәтләндерү җәймәләрендә йөрү<br>3. Теш чистарту<br>4. Сулыш гимнастикасы<br>5. Музыкаль- ритмик хәрәкәтләр<br>6. Авазлар белән сәламәтләндерү | Даими | Тәрбияче, Тәр.ярдәмчесе | |
| 6. | Туклану:<br>1. Меню төзү,<br>2. Әзер продукциягә бракераж үткәрү,<br>3. Тиз бозылучан продукциягә бракераж үткәрү<br>4. Натураль нормаларның үтәлешен контрольдә тоту<br>5. Кухняда санитария-гигена таләпләрен үтәүне күзәтү | <br>Көндәлек<br>Көндәлек<br>Продукция килгәч<br>Даими<br>Көндәлек<br><br>10 көн саен | Гараева Г.А.<br>Фатыхова Г.В. | |
| 7. | Сәламәт яшәү, гигиеник тәрбия бирү бүенча санитари-агарту эшләре алып бару. | Даими | Тәрбиячеләр | |
| 8. | Гигиеник тәрбия процессларын, режим моментларын, балаларның хәрәкәт режимын күзәтү | Көндәлек | Тәрбиячеләр | |
| 9. | Балаларны гельминт чирләренә тикшерүне оештыру | График нигезендә | Тәрбиячеләр | |
| 10. | Инфекцион авырулар белән контактта булганнарны күзәтү | Инфекция очрагында | Тәрбиячеләр | |
| 11. | Төркемнәрдә санитария-дезинфекция режимнары үтәлешен тикшерү, җилләтү режимнарын контрольдә тоту. | Даими | Тәрбияче, тәр.ярдәмчесе | |
| 12. | СанПин таләпләрен үтәү буенча хезмәткәрләр белән инструктаж | Айга бер тапкыр | Гараева Г.А. | |
| 13. | Генераль җыештыруны оештыру | Айга 1тап. | Гараева Г.А. | |
| 14. | Балалар бакчасында территория чисталыгын, яшелләндерүне контрольдә тоту | Даими | Гараева Г.А.<br>Фатыхова Г.В. | |
| 15. | Травматизмны кисәтү максатыннан спорт инвентарьларының төзеклеген тикшерү | Атнага ике тапкыр | Гараева Г.А.<br>Фатыхова Г.В. | |
| 16. | Балаларның буена үлчәп, мебельләрне | Елга ике | Гараева Г.А. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | комплектлаштыру | тапкыр | Фатыхова Г.В. | |

**Сәләтле балалар белән эш планы**

| № | Эш төре | Җаваплы | Вакыты | Үтәле ше |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Сәләтле балаларны барлау. | Гараева Г.А. Фатыхова Г.В. | Сентябрь, Октябрь | |
| 2 | Тәрбиячеләрнең сәләтле балалар белән эшләү планнарын тикшерү, раслау. | МББ ДУ | Сентябрь | |
| 3 | Тәрбиячеләрнең сәләтле балалар белән эшләү алымнарын өйрәнү, үзара тәҗрибә уртаклашулар оештыру. | МББ ДУ Тәрбиячеләр | Даими | |
| 4 | Иҗади һәм методик лаборатория тулыландыру. | Тәрбиячеләр | Даими | |
| 5 | «Сәләтле бала” конкурсында катнашу. | Гараева Г.А. Фатыхова Г.В. | график буенча | |

**Балаларга патриотик тәрбия бирү буенча эш планы**

| № п/п | Эш төре | Җаваплы | Вакыты | Үтәлеш |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Балаларга Россия һәм Татарстан гербын, флагын, гимнын таныргa өйрәтү. | Тәрбиячеләр | Сентябрь | |
| 2 | Районыбыз, башкалабыз Казан турында мәгълүмат бирү. | Тәрбиячеләр | Октябрь | |
| 3 | Балаларны потриотик рухта тәрбияләү максатында әдәби әсәрләр белән таныштыру. | Тәрбиячеләр | Даими | |
| 4 | Туган илгә, туган телгә карата балаларда ярату хисе тәрбияләү. | Тәрбиячеләр | Даими | |
| 5 | Әкиятләр, җырлар, халык уеннары, бәйрәмнәрен өйрәнү. | Тәрбиячеләр | Февраль | |
| 6 | Ватанны саклаучылар көненә карата бәйрәм иртәсе уздыру. Бәйрәмгә әтиләрне, абыйларны чакыру. | Тәрбиячеләр | Апрель | |
| 7 | «Һәрвакыт булсын кояш» дигән темага рәсем конкурсы уздыру «9 май-Җиңү көнендә» митингта катнашу. | Тәрбиячеләр | Май | |
| 8 | Балалар белән Ватанны саклаучы ларга багышлап куелган һәйкәл янына барып чәчәкләр кую. Якташ язучылар, күренекле шәхесләрне барлау һәм аларның эшчәнлеге белән | Тәрбиячеләр | Даими | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | танышу. | | | |

**ГО, гадәттән тыш хәлләр һәм террорга каршы көрәш эшчәнлеге буенча эш планы**

| № | Эш төре | Җаваплы | Вакыты | Үтәлеше |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Хезмәткәрләр белән инструктажлар уздыру | МББ ДУ | Кварталга 1 тапкыр | |
| 2 | Гадәттән тыш хәлләр буенча балалар, әти-әниләр, хезмәткәрләр белән берлектә әңгәмәләр, өйрәнүләр уздыру. | Тәрбиячеләр | Әти-әниләр җыелышы графигы буенча | |
| 3 | Янгын куркынычсызлыгы, янгынга каршы көрәш эшчәнлеге буенча тәрбиячеләрнең эш планнарын раслау | МББ ДУ | Сентябрь | |
| 4 | Зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркемнәрендә янгын куркыныч-сызлыгы, янгынга каршы көрәш кагыйдәләре турында сөйләшү. | Тәрбиячеләр | Даими | |
| 5 | Балалар бакчасына килүче чит кешеләрне контрольгә алу һәм теркәү өчен журнал булдыру. | Тәрбиячеләр | Сентябрь даими | |
| 6 | Гадәттән тыш хәлләрне исәпкә алу өчен журнал булдыру. | МББ ДУ | Сентябрь | |

**2.Урыннарда үткәрелүче тренировкалар**

| № | Эш төре | Җаваплы | Вакыты | Үтәлеше |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Янгын вакытында барлык балаларны, хезмәткәрләрне эвакуа-цияләргә өйрәнү. | МББ ДУ | Квартал-га 1 тапкыр | |
| 2 | Мәктәпкәчә төркемнең аерым урыннарында килеп чыккан янгын вакытында үз-үзеңне тоту буенча тренеровкалар | МББ ДУ | Квартал-га 1 тапкыр | |
| 3 | Террор куркынычы янаганда үз-үзеңне тоту. | МББ ДУ | Ноябрь | |
| 4 | Янгын сүндерү чаралары белән эшләү күнекмәләрен өйрәнү. | МББ ДУ | Декабрь | |

**Җәйге чорга сәламәтләндерү планы**

| № | Эш төре | Җаваплы | Вакыты | Үтәлеш |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Яшь һәм шәхси узенчәлекләрен исәпкә алып балаларга оптималь шартлар тудыру. | Тәрбиячеләр | Июнь | |
| 2. | Ядегәр авылы фельдшерлык пукты белән берлектә һәр балага аерым сәламәтләндерү төрләрен билгеләү. | Тәрбиячеләр | Июнь | |
| 3. | Балаларны авырмыйча яшәү рәвешенә табигый чыныгу юлы | Тәрбиячеләр | Җәйге чорга | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| <br><br><br><br>4.<br><br>5.<br>6. | белән өйрәтү:<br>а)һава,кояш ванналары<br>б)чирәмдә,комда яланаяк йөрү<br>в)авызны үлән сулары белән чайкау.<br>Елга, күлләргә, болынга экскурцияләр оештыру<br>Хәрәкәтле уеннар оештыру<br>Балаларны сәламәт яшәү рәвеше алып барырга өйрәтү. | <br><br><br><br>Тәрбиячеләр<br><br>Тәрбиячеләр<br>Тәрбиячеләр | <br><br><br><br>План буенча<br><br>Даими<br>Даими | |

**Коррупциягә каршы көрәш буенча алып барылучы эш**

| № | Эш төре | Җаваплы | Вакыты | Үтәлеше |
|---|---|---|---|---|
| 1 | “Коррупциягә – юк!” стендтын яңарту. | Гараева Г.А. | Даими | |
| 2 | Хөкүмәт тарафыннан коррупциягә каршы эшчәнлек буенча чыгарылган документларны өйрәнүгә тәкъдим итү. | Гараева Г.А. | Ел дәвамында | |
| 3 | Коррупциягә каршы эшчәнлек буенча һәртөрле методик әдәбият булдыру өстендә эш. | Гараева Г.А. Фатыхова Г.В. | Ел дәвамында | |
| 4 | Ата-аналар җыелышларында чыгышлар. | Тәрбиячеләр | График буенча | |

**Күргәзмәләр**

| № | Эш төре | Җаваплы | Вакыты | Үтәлеше |
|---|---|---|---|---|
| 1 | “Без коррупция турында ниләр беләбез?” (Әти-әниләр өчен күчмә папка) | Фатыхова Г.В. | Октябрь | |
| 2 | “Халыкара коррупциягә каршы көрәш көне” (Әти-әниләр өчен күчмә папка) | Фатыхова Г.В. | Декабрь | |

**Балалар белән эш**

| № | Эш төре | Җаваплы | Вакыты | Үтәлеше |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Шөгыльләрдә коррупциягә каршы эшчәнлек буенча әңгәмәләр кертү | Тәрбиячеләр | Ел дәвамында | |

**Җәйге сәламәтләндерү чорына**
**2020– 2021 уку елына эш планы**

**Максат:**

- балалар бакчасында балаларның сәламәтлеген ныгыту һәм җәйге чорны нәтиҗәле итеп үткәрү өчен шартлар тудыру.
- балаларның һәрьяклап үсешен тәэмин итү юнәлешендә яңа технологияләрне, үрнәк тәҗрибәләрне киң кулланып, балаларның сәламәтлеген саклау, аларны физик яктан ныгыту буенча нәтиҗәле эш алып баруны дәвам итү.

**Бурычлар:**

- балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, балаларда сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру;
- куркынычсызлык күнекмәләре тәрбияләү, юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнүне камилләштерү;
- балаларның җәйге ялын оештыру мәсьәләсендә ата-аналарның гомуми педагогик культура дәрәҗәсен үстерү.

| № | Үткәреләсе чаралар | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| **1.** | ***Гомуми оештыру эшләре:***<br>1.Бакчаның эш планына нигезләнеп чараларны оештыру.<br>2.Кечкенәләр төркемнәргә яңа балалар кабул итү, адаптация чорын үткәрү. | 31.05.21 | Гараева Г.А.<br>Фатыхова Г.В. |
| **2.** | ***Методик эшләр:***<br>1. Тәрбиячеләр өчен консультацияләр үткәрү:<br>- “Балаларда кояштан ничек сакларга”.<br>- “Травмаларны булдырмау чаралары”.<br>- “Тәрбияче бар яктан да үрнәк булырга тиеш”.<br>2. ФДББС таләпләренә туры китереп, әйләнә-тирә белән таныштыру, сөйләм үстерү, иҗади –сәнгать үсеше, театр эшчәнлеген, сюжетлы – рольле уеннарны мөмкинлектән чыгып һәм темасына яраклаштырып саф һавада оештыру.<br>3. Педагоглар арасында бәйгеләр:<br>- “Иң матур чәчәк түтәле, мәйданчык”.<br>- “Уку елына иң яхшы әзерләнгән төркем”.<br>- “Табигый материаллар белән бизәлгән иң матур мәйданчык”. | Июнь-август<br><br><br><br>Июнь<br><br><br><br>Август<br>Ай саен<br>Июнь | Гараева Г.А.<br><br>Тәрбиячеләр |
| **3.** | ***Сәламәтлекне саклау һәм ныгытуны оештыру эшләре:***<br>1. Балалар бакчасында җәйге сәламәтләндерү өчен шартлар тудыру.<br>2. Иртәнге кабул итү һәм гимнастиканы урамда уздыру.<br>3. Спорт-сәламәтләндерү чарасы буларак бәйрәм “Без көчле, батыр, җитез!”<br>4. Сәламәтләндерү буенча мәгълүматлар булдыру:<br>- “Суда сак булыгыз”<br>- “Кояш һәм һава ванналары”<br>- “Балалар авыруларын кисәтик”<br>- “Беренче ярдәм күрсәтү”<br>- “Йогышлы эчәк авыруларын булдырмау чаралары”<br>- “Сәламәт буласың килсә”<br>- “Сак булыгыз: агулы гөмбәләр”.<br>5. Су эчү режимын оештыру.<br>6. “Су, кояш һәм һава - безнең якын дусларыбыз!”<br>7. Ата-аналар өчен җәйге сәламәтләндерү чаралары буенча мәгълүматларны яңартып тору.<br>8.Ашарга алу, балаларны ашату режимын саклау.<br>9. Төркемнәрне җилләтү режимын саклау.<br>10. “Сәламәтлек көне” - спорт,күңел ачу чаралары | Июнь-август<br><br><br><br>Июнь-август | Администрация<br><br>Тәрбиячеләр<br><br>Администрация<br><br>Тәрбиячеләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | “Су белән уеннар” күңел ачу чарасы | | |
| **4.** | ***Педагогик эшчәнлек***<br>**Балалар белән эш:**<br>1. Максатчан сәяхәтләр оештыру:<br>а) урам белән танышу;<br>б) күңелле юл чатында.<br>2. Әңгәмә:“Юл йөрү кагыйдәләрен беләсеңме?”<br>3. “Уенчыклар урамында” уенчыклар – дидактик уеннар, сюжетлы уеннар, транспорт төрләре һәм шәһәр макеты уены оештыру.<br>4. Җәйге чорда физик тәрбия буенча уен, шөгыльләр оештыру.<br>5 . Мөмкин кадәр күбрәк саф һавада булу.<br>6. Урам уенчыкларын төрләндерү юлы белән саф һавада хәрәкәт эшчәнлеген арттыру .<br>7. Көн дәвамында төрле чыныктыру чараларын үткәрү (кояш ваннасы, яланаяк йөрү һ.б.)<br>8. Хәрәкәтнең төп төрләрен һәм координацияне үстерү буенча индивидуаль эшләр алып бару.<br>***Тәрбиячеләр белән эш:***<br>д) “Табигый материаллар белән бизәлгән иң матур мәйданчык”<br>е) Яшелчә, чәчәк газоннарына бәйге.<br>ж) “Чәчәкләр бәйрәме” конкурсында катнашу. | Июнь-август<br><br>Июнь-август | Гараева Г.А.<br>Фатыхова Г.В.<br><br>Тәрбиячеләр |
| **5.** | ***Аталар һәм балалар белән берлектә проект төзү:***<br>- “Без хезмәт яратабыз” – участокта хезмәт тәрбиясе;<br>- “Чәчәкләр көне” – җирне матурларга өйрәтү; клумбадагы чәчәкләрне тәрбияләп, күзәтүләр алып бару; | Июнь-август | Барлык төркем тәрбиячеләре ләре,<br>ата- аналар |
| **6.** | ”***Табигать дөньясында”***<br>- табигатьтә булган үзгәрешләрне күзәтү:<br>- бөҗәкләр белән таныштыру, аларны күзәтү, әңгәмә кору;<br>- төркемнәрне гөлләр белән тулыландыру;<br>- табигать материалларыннан сувенирлар эшләү;<br>- күзәтүләр, әңгәмәләрдән чыгып рәсемнәр ясау. | | |
| **7.** | ”***Экологик һөнәр”***<br>- табигатьне саклаучылар турында сөйләшү;<br>- парк, аллея, яшелчә бакчасы һәм экологик сукмак буйлап сәяхәт;<br>- табышмаклар әйтү, хикәя төзү, шигырь уку, матур әдәбият әсәрләрен өйрәнү. | Июнь-июль | Тәрбиячеләр |
| **8.** | ”***Яшел даруханә”***<br>- дару үләннәре белән таныштыру, аларны әзерләү, җыю, киптерү серләренә төшендерү,<br>- файдалы һәм агулы үләннәр турында әңгәмә,<br>- үсемлекләрне чүлмәкләргә утырту. | Июнь-август | Тәрбиячеләр |
| **9.** | ***Бәйрәмнәр, спорт ярышлары, күңел ачу кичәләре:***<br>- “Балачак бәйрәме” – 1 июнь – балаларны яклау көне;<br>- “Күңелле сабантуй”;<br>- “Су, кояш һәм һава – безнең якын дусларыбыз” – су белән уеннар;<br>- “Чәчәкләр аланы” – болынга сәяхәт; | | Тәрбиячеләр<br><br>Тәрбиячеләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **1 0.** | - чәчәкләр бәйрәмендә катнашу;<br>- "Туган җирем – Татарстан" – республика көнен бәйрәм итү.<br>***<u>Ата-аналар белән эш:</u>***<br>1. Төркемнәрдә ата-аналар почмагын яңарту.<br>2. "Сәламәтлек почмагын" яңарту.<br>3. Мәйданчыкны бизәү һәм яшелләндерү эшендә ата-аналарны катнаштыру.<br>4. Ата-аналар белән берлектә проект эшчәнлеген оештыру. | Июнь-август<br><br>Июнь-август | Гараева Г.А.<br>Фатыхова Г.В. |